# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бутлеровка авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

2024 елның 18 октябрендәге 2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бутлеровка авыл торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бутлеровка авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндез укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокլы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**